ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2026 Олы Кайбыч ав. №223

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча виртуаль укыту-консультация пункты булдыру турында» 2025 елның 16 маендагы 237 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча виртуаль укыту-консультация пункты булдыру турында» 2025 елның 16 маендагы 237 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«ГО һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә Кайбыч муниципаль районы халкына мәгълүмат бирү һәм консультация бирү, шулай ук мобилизация чорында барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләрдән саклану ысулларын хәрби хәл гамәлдә булган чорында, сугыш вакытында, хәбәр итү сигналлары буенча гамәлләр тәртибен, беренче ярдәм күрсәтү алымнарын, күмәк һәм индивидуаль яклау чараларыннан файдалану кагыйдәләрен, янгын куркынычсызлыгы һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгы кагыйдәләрен мөстәкыйль өйрәнү;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе Д.А.Бәдертдиновага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров